| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** 26.07.2022 | Казан ш. | **БОЕРЫК** 630 - п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгы белән расланган Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасын раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгы белән расланган Төбәк дәүләт экология контроле кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга булган җаваплар контрольлектәге зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында раслый торган тикшерү сораулары исемлеге) формасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 пунктта:

«Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» дигән икенче графаның 16 нчы соравын түбәндәге редакциядә бирергә:

«16. Су хаҗәлыгы системасын эксплуатацияләгәндә түбәндәгеләрне тыю турындагы таләпләрнең үтәлеше тәэмин ителгәнме:

- санитар чистартуга, зарарсызландыруга дучар ителмәгән агынты суларны су объектларына агызуны тыю турында (су объектларына рөхсәт ителгән йогынты нормативларыннан һәм су объектларында пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрациясе нормативларыннан чыгып)?

- йогышлы авыруларны китереп чыгаручылар, шулай ук пычраткыч матдәләр булып, алар өчен чик дәрәҗәдә рөхсәт ителгән концентрацияләрнең нормативлары билгеләнмәгән агынты суларны су объектларны ташлауны?»;

«Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» дигән икенче графаның 18 нче соравында «радиоактив калдыкларны күмү пунктлары» сүзләреннән соң «, шулай ук балык хуҗалыгы билгеләнешендәге су объектлары суларында чик дәрәҗәдә рөхсәт ителә торган концентрацияләре билгеләнмәгән пычраткыч матдәләр белән территорияләрне пычрату» сүзләрен өстәргә.

2. Хокукый тәэмин итү бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М.Шиһаповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков